# Мәктәп хәбәрчесе

**№9**
(№30)
ноябрь
2021 ел

Түбән Майна урта мәктәбе газете


Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


## 4 нче ноябрь – Халыклар бердәмлеге көне!



## 6 нчы ноябрь – Татарстан Конституциясе көне




Хөрмәтле кардәшләр! Моннан 29 ел элек, 1992 нче елның 6 нчы ноябрендә Татарстан Республикасының Конституциясе кабул ителде. Төп канунга ия булу Республиканың һәм татар халкының абруен дөньякүләм дәрәҗәгә күтәрде, Татарстанның дәүләтчелеген ныгытудагы иң мөһим адымнарның берсенә әверелде. 2005 нче елдан алып 4 нче ноябрь Халыклар бердәмлеге көне буларак билгеләп үтелә. Бу ике бәйрәмнең бер вакытка туры килүе үзе үк тирән символик әһәмияткә ия. Чөнки алар икесе дә, барча халыкларның дус һәм бер-берсенә ихтирамлы булган хәлдә да тотрыклы үсешен, чын федерализм принципларының какшамаслыгын игълан итә.

Барыгызны да **Халыклар бердәмлеге көне** һәм **Татарстан Конституциясе көне** белән чын күңелдән тәбрик итәбез! Газиз татар халкыбызның һәм илебездә яшәүче барлык халыкларның да тормышлыры иркен, киләчәкләре якты булсын дигән теләктә калабыз.

*Мәктәп җитәкчелеге*

## Бәйрәмегез белән, ӘНИЛӘР!

*/ Мөхәррир сүзе /*



**Әниләр...** Бәйрәмегез табигатьнең беренче карларга күмелгән чорына туры килсә дә, Сез барында күңелләрдә һәрвакыт яз кояшы балкый. Көннең таңы газизең янәшәдә булганда атса, кеше сабыйлыктан беркайчан да чыкмый. Сүздә генә аннан китәбездер. Чөнки әнинең назлы тавышы, иркәләве көн саен тансык. Кеше ничә яшьтә булса да, янында кадерлесе булганда киңәшкә, ярдәмгә мохтаҗлык кичерми. Дөнья мәшәкатьләреннән арысаң, бераз кыенлыкка тарысаң – **ӘНИ кирәк**. Чиксез шатлыкка, уңышка ирешсәң – **ӘНИ кирәк**. Әниләребезнең гомер буе күңел тәрәзәсеннән безне, баласын, күзәткәнне онытмыйк. Йөрәге белән һәр хәрәкәтебезне, һәр мизгелебезне тоеп, белеп тора. Һәр бала әнисенең олы шатлыгы да, сөенече дә, борчуы да. Әгәр дә шуларны истән чыгармыйча, ӘНКӘЙЛӘРНЕҢ кадерен белсәк, күңел кояшыбыз мәңге балкыр.

Илебездә ноябрь аеның һәр соңгы якшәмбесендә билгеләп үтелә торган бәйрәм әниләрне котлауга багышланган. Бу бәйрәм – әниләргә ярату хисләрен тагын бер кат җиткерү өчен яхшы сәбәп. Шул уңайдан безнең мәктәптә бу чараны уздыруга һәр сыйныфка аерым бирем бирелде. Әниләрне котлау өчен барлык сыйныфлар да видеокотлау төшерерп җибәрде. Аларга кулдан ясалган открыткалар, чәчәкләр тапшырылды. Әниләргә булган хөрмәт матур бәйрәмнәрдә генә калмыйча, гомер буе дәвам итсен дигән теләктә калабыз. Һәр әнигә саулык, кояштай озын гомер, балаларыннан игътибар телибез.



*"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе*

---

## ЮИД яңалыклары

*/ Мәктәп тормышы /*




*Юл билгеләре безгә*
*Бик күп нәрсә әйтәләр.*
*Кирәк чакта боералар,*
*Кайвакыт кисәтәләр.*

*Һәлакәтләр булмасын дип,*
*Телидер һәрбер йөрәк.*
*Шуңа күрә юл йөргәндә,*
*Бик сак булырга кирәк.*

"Тормыш – хәрәкәт, хәрәкәттә – бәрәкәт" ди халык мәкале. Чыннан да, яшәешебезне юл йөрүдән башка күз алдына китерүе дә кыен. Шул ук вакытта юллар зур куркыныч чыганагы да булып тора. Ел саен ООН исәпләүләре буенча, юл һәлакәтләрендә 1 миллион 300 мең кеше гомере өзелә, 20 дән 50 миллионга кадәр кеше төрле тән җәрәхәтләре ала. Россия юлларында көн саен 3 - 4, ел буена якынча 1300 тирәсе бала үлә.

Балаларны, әти–әниләрне мондый зур хәсрәтләрдән саклап калу максатыннан безнең мәктәптә ЮИД отряды эшләп килә. Сыйныфтан тыш чараларда, сыйныф сәгатьләрендә балалар юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнә. Төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларда, конкурс, смотрларда, викториналарда катнаша.

Бу айда 1-5 сыйныф укучылары өчен "Яктыртыл" дип аталган чара, 6-11 сыйныфлар өчен юл һәлакәтендә һәлак булучыларны искә алу көненә багышланган сыйныф сәгатьләре үткәрде. Шулай ук, 1 сыйныф укучыларын "Яшь ЮИДчылар" отрядына кабул иттек.

*Руфия Гафиятуллина, VIII сыйныф һәм ЮИД отряды җитәкчесе*

## Оста куллар түгәрәге



Мәктәптә укыган вакытлар, күңелле бәйрәмнәр, кызыклы дәресләр, яраткан укытучылар белән үткән иң кадерле, бәхетле чор хәтергә онытылмас мизгелләр булып уелып кала. Мәктәп бит ул белем йорты гына түгел, биредә фән нигезләре белән беррәттән бала күңеленә тәрбия орлыклары да салына. Мәктәптә укучыга хезмәт тәрбиясе, һөнәр сайларга юнәлеш тә бирелә. Шундый тәрбияви эшчәнлектә иң әһәмиятле урынны дәрестән тыш үткәрелгән чаралар алып тора.

Сүзем мәктәптә эшләп килгән "Оста куллар" түгәрәге турында барачак. Әлеге түгәрәкне киң күңелле, кул эшенең остасы Рузилә апалары алып бара. Түгәрәк атнасына ике көн, ягъни дүшәмбе, чәршәмбе көннәрендә эшли. Укучылар ул көннәрне түземсезлек белән көтеп алалр. Катлаулы тоелган дәресләрдән соң,ниһаять, үзең яраткан эш белән шөгыльләнергә мөмкин бит! Ә күңелең теләгән эш белән шөгыльләнү инде ул беркайчан да ялыктырмый.

Рузилә апалары әлеге түгәрәктә балаларга бик күп нәрсәләр өйрәтә. Кызлар тегәргә, бәйләргә, балчыктан төрле сыннар ясарга, тәмле салатлар, чәч кыстыргычлары, матур-матур брошкалар ясарга өйрәнәләр. Һәр ел фасылына табигый материаллардан төрле композицияләр ясап конкурсларда катнашалар. Моның белән генә чикләнеп калмыйлар, кызлар өчен бик мөһим булган макияж һәм прическа серләрен дә ача аларга апалары.

Рузиләнең фантазиясенә, энергиясенә, осталыгына һәм башкалар белән уртаклаша белүенә гаҗәпләнми мөмкин түгел. Һәр балага индивидуаль якын килә белә, балаларның психологиясен дә бик яхшы аңлый. Кызлар түгәрәккә бик шатланып йөриләр. Әлеге дәресләр вак моториканы, образлы фикерләүне, иҗади активлыкны үстерүгә ярдәм итә. Башланган эшне ахырына кадәр җиткерә белүне формалаштыра. Пөхтәлек, тырышлык, хезмәткә сакчыл караш тәрбияли, кеше кулы белән ясалган матурлыкка мәхәббәт тәрбияли. Түгәрәккә йөргән балалар, район күләмендә төрле иҗади конкурсларда актив катнашып, югары урыннар да алып торалар.

Мин, шәхсән үз исемемнән һәм дә түгәрәккә йөрүче барлык балаларның әти-әниләре исеменнән, Рузиләгә рәхмәтемне белдерәм. Хезмәтең өчен Аллаһның рәхмәтләре булсын сиңа, Рузилә! Сиңа эшеңдә зурдан-зур уңышлар, иҗат чишмәләрең беркайчан да кипмәсен, тулыланып торсын.

*Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныфлар укытучысы*

## /Котлыйбыз! /

Ноябрь аенда туган көннәрен билгеләп үтүче I сыйныф укучысы **Галиаскәрова Айшәне**, II сыйныфтан **Нурматова Асияне**, VII сыйныфтан **Хәйруллин Айназны**, VIII нче сыйныфтан **Гафиятуллин Саматны**, XI сыйныфтан **Насыйрова Сараны** ихластан бәйрәмнәре белән котлыйбыз. Киләчәкләреңең якты булуларын телибез. Укуларында уңышлар юлдаш булсын!


Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева
Виктория Нукина
Зөлфирә Сафиуллина
Сара Насыйрова
Рузилә Мөхәммәтова

## БДИ – 2022, үзгәрешләр көтелә

“Мәктәп хәбәрчесе”нең алдагы саннарында имтиханнарны алдан сайлап, дөрес әзерләнү, вакытны дөрес бүләргә өйрәнү турында мәгълүмат биргән идек. БДИ төгәллекне таләп итә торган хезмәт нәтиҗәсе булганга, быелгы имтиханнарга кагылышлы үзгәрешләр турында тулырак мәгълүмат җиткерәбез.




БДИ-2022 гә килгәндә, үзгәрешләр, чыннан да, шактый булачак. Алай да имтиханны катлауландыру бурычы куелмый. Эш шунда ки, нәкъ менә 2022 елда мәктәпне Федераль дәүләт белем бирү стандартлары (ФГОС) буенча беренче сыйныфтан алып укыган балалар тәмамлаячак. ФГОС буенча фактлар, даталар яки формулаларны истә калдыру гына түгел, аларны гамәли куллана белү дә җаләп ителә. Мәктәп баланы анализларга, системалаштырырга, сайлап алырга һәм комбинацияләргә, алар нигезендә нәтиҗәләр ясарга өйрәтергә тиеш.

Мәҗбүри бирелә торган **рус теле** фәненнән ФИПИ экспертлары 1-2 минут эчендә чишелә торган, тыныш билгеләренә кагылышлы өч "кыска" биремнәрне алып ташладылар. Алар урынына шактый гына күләмле булган текстларны анализлау өчен биремнәр барлыкка килде. Ә имтихан тапшыру вакыты артмаган. Чыгарылыш сыйныф укучылары бөтен эшне башкарып өлгерерме, юкмы – үзләреннән тора. Һәр биремне үтәү вакыты укучының шәхси характеристикасы, ул үз темпында эшли. Ул игътибарлылыкка, функциональ укуга, хәтер эшенә, баланың эмоциональ торышына бәйле. Имтихан эшенең 1 нче өлешендә укылган текстның төп мәгълүматын кыскарта белүне тикшерә торган состав биреме төшереп калдырылды. Аның урынына текстның стилистик анализын башкара белүен тикшерә торган состав биреме кертелгән. 16 нчы биремнең формулировкасы, бәяләү һәм спектры үзгәртелде, тыныш билгеләренә киңәйтелгән анализ кертелде. 70-150 сүз күләмендәге инша бәяләү нормалары төгәлләштерелгән. Беренчел балл 59 дан 58 гә кадәр төшерелгән.

Шулай ук **математика** укытучылары да, укучылар да борчыла: профильле имтиханда комплекслы саннарга биремнәр барлыкка килгән. (9 нчы бирем), функцияләр белән эш итә белүне тикшереп торучы һәм (10 нчы бирем), ихтималлылык һәм статистика теориясе телендәге реаль ситуацияләрне модельләштерә белүне тикшерүче, гади очракларда вакыйгаларның ихтималын ачыклаучы 10 бирем өстәлә. Бәяләү системасына үзгәреш кертелгән: геометрик фигуралар, координатлар һәм векторлар белән эш итә белүне тикшерүче 13 югары дәрәҗәдәге биремне үтәгән өчен максималь балл 3 кә тигез; практик эшчәнлектә һәм көндәлек тормышта алган белемнәрен һәм күнекмәләрен куллана белүне тикшерә торган 15 югары дәрәҗәдәге биремне үтәү өчен максималь балл 2гә тиң. Биремнәр саны 19 дан 18 гә кадәр кимеде, барлык эшләрне башкару өчен максималь балл 31 гә тигез. Шулай ук биремнәрнең урнашу тәртибе дә үзгә. Урта сыйныфларда ук үтелгән функцияләр һәм ихтималлык теориясенә (теория вероятности) тагын бер бирем өстәлде.

Безнең мәктәп укучыларының күпчелеге имтихан алганда биология, химия, җәмгыять белемен сайлый. Алар барысы да үзгәреш кичерә. Тест өлешендә дөрес җаваплар саны элекке елларда билгеле булган булса, киләсе ел имтиханнарында аларның саны билгесез. **Биология** белән **химиядән** билгесезлекне табар өчен графиклар, таблицалар биреләчәк һәм башка предметлар белән бәйле биремнәр дә урын алачак. Физика, математикага бәйләнешле мәсьәләләр китереләчәк. Биологиядән БДИга да, укытучылар ышандырганча, олимпиада дәрәҗәсендәге биремнәр дә өстәлә. Аларны шулай ук, математика, химия, физика белән чиктәш дияргә була. Шуңа күрә фәнара элементәләр имтиханда күренәчәк.

**Җәмгыять белеменнән** дә шактый гына үзгәрешләр бар. Кайбер биремнәр төшерелеп калдырылды. Кайберләренең тәртибендә үзгәрешләр бар. Тикшерелә торган осталык буенча бер-берсен кабатлый торган биремнәр бетерелде. 1 нче өлештән 1, 2 һәм 20 биремнәр төшереп калдырылды. Сорау һәм тәкъдим графигын анализлауда үзгәрешләр күзәтелә. Кечкенә күләмле инша язуны таләп итә торган альтернатив бирем кертелмәгән. 2 нче өлешкә Россия Федерациясе Конституциясе һәм законнары буенча бирем кертелгән (2022 ел нумерациясе буенча 23 бирем). Тәкъдим ителгән тема буенча җентекле җавап планын төзү состав биременә кертелгән, ул план төзүне һәм кечкенә инша элементларын үз эченә алган. Максималь балл 64 тән 57 гә кадәр төшерелде. Эшне башкаруның гомуми вакыты 235 тән 180 минутка кадәр кыскартылды.

**Рус әдәбиятыннан** да БДИ да үзгәрешләр аз түгел. Әдәби материал баетылган: XIX гасырның икенче яртысындагы поэзия, XXI гасырның Ватан әдәбияты киңрәк тәкъдим ителгән, чит ил әдәбияты да кертелгән. 7-11 нче биремнәрдә чит ил лирикасы әсәрләре төрле төр биремнәрне кыскача һәм җаваплы формалаштыру өчен терәк текст сыйфатында җәлеп ителергә мөмкин. 6 һәм 11 биремнәрне үтәгәндә, чит ил әдәбиятыннан да контекст белән чагыштыру өчен мисал сайлау рөхсәт ителә. 2 нче өлештәге иншалар темаларының кайбер формулировкаларында Ватан яки чит ил әдәбияты әсәрләренә мөрәҗәгать итү мөмкинлеге каралган (катнашучы сайлау буенча). База дәрәҗәсендәге биремнәр саны (кыска җавап белән) 12 дән 7 гә кадәр кыскартылды. *(Дәвамы 3 нче биттә)*



## Мәдәният өлкәсендәге яңалык – “Пушкин картасы”



Мәдәният диюгә бала чагым, авылдашларым искә төшә. Ни өчен дисезме? Чөнки бала чакта бик еш бәйрәмнәргә, киноларга, төрле чараларга мәдәният йортына агыла идек. Әйе, үткәнне хәзерге тормыш белән бер ничек тә чагыштырып булмый шул. Вакытлар үтә, заманалар үзгәрә, буыннар яңара – без киләчәкне кайгыртырга тиешбез.

Сер түгел, балаларыбыз күп вакытын телефонда, компьютер янында социаль челтәрләрдә үткәрә. Яшь буынның укуга карашлары көннән-көн сүлпәнәя, шулай ук кешеләр белән РЕАЛЬ аралашу да кими. Балаларыбыз милләтебезнең, үзебезнең төбәк халыклары мәдәниятен белеп һәм аңлап, сәнгать казанышлары турында хәбәрдар булып үссәләр, төрле халыклар арасында аңлашылмаучанлыклар да кимрәк булыр иде.

Шөкер, дәүләтебез яшьләрнең мәдәни үсешенә бәйле проблемаларны күреп, аны чишүнең төрле юлларын тәкъдим итә. 2014 нче елдан алып, укучылар өчен мәдәният программасы эшли башлаган иде. Уку елы башында укучыларга мәдәни көндәлек тапшырыла һәм ел дәвамында алар нинди сәнгать чарасын каравын билгеләп бара. Ел азагында актив укучыларга бүләкләр тапшырыла. Әлеге программа бүгенгесе көндә дә эшләп килә.

Быелгы уку елы башында Россиядә **“Пушкин картасы”** программасы гамәлгә керде. Бу проект үсмерләрне мәдәни чараларга җәлеп итүнең яңа баскычы. Аның төп максаты – хәзерге заман шартларында яшь буынга патриотик тәрбия бирү, аларның тәрбияле, әхлаклы шәхесләр булып формалашуы өчен шартлар булдыру. Әлегә карта виртуаль итеп кенә эшләнелгән, әмма киләчәктә аның пластик варианты да гамәлгә кертеләчәк. Картаның балансы быел 3000 сум, 2022 елда 5000 сум тәшкил итәчәк. “Пушкин картасы”ннан 14 яшьтән 22 яшькә кадәрге яшүсмерләр һәм яшьләр файдалана ала. Картадагы акчаны бары тик музейларга, театр, концертларга һәм бу проект программасына кертелгән башка мәдәни чараларга билет алу өчен генә тотарга була. Тагын бер мөһим үзенчәлек – “Пушкин картасы” балансын мөстәкыйль тулыландырырга ярамый, аңа акчалар елга бер тапкыр дәүләт фондларыннан күчерелә. 3 мең сумны ел ахырына кадәр файдаланып бетерә алмасаң, аны киләсе елга күчерү мөмкинлеге дә каралмаган. Мәдәни чаралар турында тулырак мәгълүматны “Культура.РФ”, “Госуслуги. Культура” порталларыннан һәм “Пушкин картасы” афишасыннан белергә була.

Безнең укучыларыбыз да “Пушкин картасын” булдырдылар һәм район күләмендә үткәрелгән чараларга йөреп торалар. Узган айда район үзәгендә уздырылган “Яшьләргә”дигән мастер класслар карарга бардылар. Укучылар әлеге мөмкинлекне уңай кабул иттеләр, һәм киләчәктә дә “Пушкин картасы” чараларына йөрергә теләкләре зур.

***Рузилә Хәйруллина, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары***




*(Дәвамы, башы 2 нче биттә)* Шуның нәтиҗәсендә биремнәр нумерациясе үзгәрде. Сайлау өлешендә биремнәр саны арттырылды һәм 2 нче өлешендә «сәнгать диалогы»на таянып язылган бишенче тема өстәлә. Кайбер биремнәрне үтәүгә карата таләпләр үзгәртелде: тәкъдим ителгән текст белән чагыштыру өчен икесен түгел, ә бер әсәрне сайлап алу таләп ителә. Әлеге биремнәрне бәяләү критерийлары төгәлләштерелде. Инша күләменә таләпләр дә арттырылган (сүзләрнең минималь саны – 200). “Теоретик-әдәби төшенчәләргә таяну" критерие буенча инша бәяләүнең максималь баллы 2 дән 3 баллга кадәр арттырылды. Грамоталылыкны бәяләү критерийлары кертелде. Барлык имтихан эшен башкарган өчен максималь беренчел балл 58 дән 55 кә төшерелгән.

Күргәнебезчә, барлык фәннәр дә үзгәреш җилен кичерә. Бу укучыга да, укытучыга да җаваплылык өсти. Әтиәниләр дә бу нечкәлекләрне аңлап, балаларга игътибарлырак булсак иде. Әлбәттә, әзерләнү мөмкинлеге бездә бар, беренчедән, бала аз, укытучыдан вакыт күп бүленә. Икенчедән, интернет ресурслардан файдалану мөмкинлеге дә киң. Бюджет төркемнәренә эләгү өчен, күпчелек университетларга кимендә 60 балл яки югарыракны җыю мөһим. Берничә ВУЗны сайлап, узган елгы балларны карарга кирәк. 80-90 балл белән, я булмаса 60 балл белән кереп буламы? Үз көчеңне чын-чынлап исәпләргә киңәш итәр идем.

***Рифкать Туктамышев, биология-химия укытучысы***